КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 август г.Казань № 677

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 4 июль, 783 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибе;

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне;

төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия составын.»;

әлеге карар белән расланган Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибендә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы милкендәге төгәлләнмәгән төзелеш объектларын инвентаризацияләү һәм хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – Эшче төркем)» сүзләрен «төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия)» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Эшче төркем» сүзләрен «ведомствоара комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

беренче абзацта «Эшче төркем» сүзләрен «ведомствоара комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Эшче төркемгә» сүзләрен «ведомствоара комиссиягә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне, төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия составын (карарга теркәләләр) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 2 октябрь, б-2186 нчы; 2023 ел, 3 июнь, б-1257 нче боерыклары үз көчен югалткан дип таныrга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 21 август, 677 нче
карары редакциясендә)

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына (алга таба – объект) карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) күмәк киңәшмә орган булып тора, төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеше, реконструкциясе Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган һәм төгәлләнеп бетмәгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектын төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларының федераль реестрына, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларының төбәк реестрына кертү нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 июлендәге 1333 номерлы карарының 1 пунктында күрсәтелгән идарә карарларын (алга таба – идарә карары) кабул итә.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Ведомствоара комиссия бурычлары

2.1. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары – объектларга карата идарә карарларының берсен карата кабул итү һәм идарә карарларына, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки

өлешчә гамәлгә ашырылган, тәгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы тәгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче карары белән расланган Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, тәгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы тәгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибе нигезендә тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары санын киметү чаралары планына кертелгән объектларга карата да үзгәрешләр кертү.

2.2. Ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

республика башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан ведомствоара комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук үз мәнфәгатьләрен кайгырта торган мәсьәләләрне тикшергәндә объектлар караган оешмалар вәкилләрен үз утырышларына катнашуга җәлеп итәргә һәм тыңларга. Әлеге вәкилләр ведомствоара комиссия утырышларында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының чакыруы буенча катнаша;

ведомствоара комиссия утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар һәм бәяләмәләр бирү өчен ведомствоара комиссия эшчәнлегенә белгечләр һәм төрле белем өлкәләре экспертларын җәлеп итәргә.

## III. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү тәртибе

3.1. Ведомствоара комиссия составына ведомствоара комиссия комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары керә. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3.2. Үзенә куелган бурычларны үтәү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, тәгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән көннән 15 эш көне эчендә идарә карарларының берсен кабул итү турында ведомствоара комиссия каравына тәкъдим чыгара. Утырыш йомгаклары буенча тәкъдимнәр кергән көннән алып 10 эш көне эчендә ведомствоара комиссия, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеше, реконструкциясе Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган һәм тәгәлләнеп бетмәгән, тәгәлләнмәгән төзелеш объектын тәгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларының федераль реестрына, тәгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларының төбәк реестрына кертү нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 июлендәге 1333 номерлы карарының 6 – 8 пунктларында билгеләнгән критерийлар җыелмасын исәпкә алып, идарә карарларының берсен кабул итә.

3.3. Ведомствоара комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми

санынннан кимендә өчтән икесе катнашкан булса, хокуклы дип санала.

3.4. Ведомствоара комиссия утырышларында катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, ведомствоара комиссия әгъзасы, ведомствоара комиссия утырышы көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бу хакта ведомствоара комиссия секретарена хәбәр итәргә тиеш.

3.5. Ведомствоара комиссия утырышын ведомствоара комиссия рәисе яисә, ул булмаган очракта, аның йөкләмәсе буенча ведомствоара комиссия рәисе урынбасарларының берсе алып бара.

3.6. Ведомствоара комиссия рәисе:

ведомствоара комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышы датасын билгели;

ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

ведомствоара комиссия утырышларында рәислек итә;

ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләренә кул куя.

3.7. Ведомствоара комиссия секретаре:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеше, реконструкциясе Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган һәм төгәлләнеп бетмәгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектын төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларының федераль реестрына, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларының төбәк реестрына кертү нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 июлендәге 1333 номерлы карарының 6 – 8 пунктларында билгеләнгән критерийлар җыелмасын исәпкә алып, объектларга карата идарә карарларын кабул итү турындагы тәкъдимнәргә анализ ясый;

ведомствоара комиссия утырышында карау өчен мәсьәләләр әзерләүдә катнаша;

ведомствоара комиссия әгъзаларына, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән затларга ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибе, аны уздыру датасы, урыны, вакыты турында хәбәр итә, шулай ук әлеге затларга ведомствоара комиссия утырышын уздыру көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле материаллар җибәрә;

ведомствоара комиссия утырышларының беркетмәләрен алып бара һәм рәсмиләштерә, ведомствоара комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

ведомствоара комиссия эшен тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

Ялда, командировкада булу, вакытлыча хезмәткә яраксыз булу чорында яисә башка сәбәпләр аркасында ведомствоара комиссия секретаре булмаган очракта, аның вазыйфалары ведомствоара комиссия рәисе йә ведомствоара комиссия рәисе вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан ведомствоара комиссия әгъзаларының берсенә йөкләнә.

3.8. Ведомствоара комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.9. Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән идарә карары ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа ведомствоара комиссия утырышы көненнән алып өч эш көне эчендә ведомствоара комиссия рәисе тарафыннан кул куела.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 21 август, 677 нче
карары редакциясендә)

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрына кертелгән төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, ведомствоара комиссия рәисе |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, ведомствоара комиссия рәисе урынбасары |
| Галиев Артур Ирек улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары, ведомствоара комиссия рәисе урынбасары |
| Камаев Радик Рафаил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлегенең баш киңәшчесе, ведомствоара комиссия секретаре |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Азин Юрий Николаевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Данилов Эдуард Юрьевич | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Җәббаров Азат Галимҗан улы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Костин Артем Петрович | «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры (килешү буенча) |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Лулаков Денис Владиславович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |
| Миңнәхмәтов Җәүдәт Мидхәт улы | «Татарстан Республикасының Инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе генераль директоры |
| Миңнуллин Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Самигулин Марат Рәшит улы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |
| Сибгатуллин Илдар Нурзад улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Ситдыйков Нияз Равил улы | «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының беренче урынбасары – Казначылык департаменты директоры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәмзина Лена Илдар кызы | «Татарстан Республикасының Техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хөснетдинов Гадел Альберт улы | «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү, фәнни-җитештерү фирмасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры. |